ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» сентябрь 2020 ел № 288

«Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбеннән акчалата түләүләр бирү тәртибен раслау турында» Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 12 маендагы 151 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актка үзгәрешләр кертү, төгәлсезлекләрне бетерү һәм аны хокукый анализ һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбеннән акчалата түләүләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 елның 12 маендагы 151 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтада (хезмәткәрләргә - Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбеннән акчалата түләүләр бирү тәртибе):

- 1 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

Оешмаларның координаторы булып район башкарма комитетының функциональ органы - Спорт һәм туризм бүлеге (алга таба - Бүлек) тора.

- 13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Бүлек ай саен, айның 5 санына кадәр Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга акчалар бирү турында заявка;

Министрлык боерыгы белән расланган рәвештә спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләрнең - яшь белгечләрнең реестрлары.»

- 14 пунктны төшереп калдырырга;

- 15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Хезмәткәрләргә - муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә акчалата түләүләрне башкару өчен район башкарма комитеты чыгымнарын финанс белән тәэмин итү Министрлык тарафыннан субсидияләр бирү юлы белән гамәлгә ашырыла. Субсидия Министрлык һәм район башкарма комитеты арасында төзелгән килешү нигезендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (алга таба - Килешү) раслаган типовой форма нигезендә бирелә.

Килешү шушы Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылган көннән алып 10 көн эчендә төзелә.»

- 16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата түләүләрне башкаруга субсидияләр Министрлык тарафыннан ай саен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының шәхси счетына күчерелә.»

- 17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Бүлек Министрлыкка хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә Килешүдә каралган сроклар һәм формалар нигезендә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга субсидиядән файдалану турында хисап тапшыра.»

- 18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Агымдагы финанс елында район башкарма комитеты тарафыннан файдаланылмаган субсидияләрнең калган өлешләре законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиеш.»

- 19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Район башкарма комитеты тарафыннан Субсидияләр бирү шартлары Министрлыкның язма таләбе нигезендә бозылганда, субсидия тиешле таләп алынган көннән алып 10 эш көне эчендә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиеш.»

- 20 пунктны төшереп калдырырга;

- 21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21. Район башкарма комитеты хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә хезмәт хакын билгеләнгән срокларда, ай саен акчалата түләүләр бирүне тәэмин итә.»

1.2. Татарстан Республикасы бюджетыннан «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен (2 нче кушымта) үз көчен югалткан дип танырга (карарның 2 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән).

2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Баженовага йөкләргә.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **И.И. Шәмсетдинов**